**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КАРАРЫ**

2020 елның 5 июне 305 №

2020 елга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы милкендә булган
мөлкәтне хосусыйлаштыруның
Фараз планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 һәм 51 статьялары, 85 статьясындагы 8 пунктның 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.2020 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга

2. Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2020 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын үтәү өчен әзерлек эшләре алып барырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми www.alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясенең рәсми www.torgi.gov.ru сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанслар, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А. Ф. Никошин

Совет Алькеевского муниципального района РТ

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль район Советының
2020 елның 5 июнендәге 305 номерлы
Карарына 1 нче кушымта

**2020 елга Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы ( программасы)**

## 1Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2020 елга Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. 2020 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 Бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2020 елда Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслanучы муниципаль казнадагы һәм оешмалар файдаланмаган муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2.Хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Мөлкәтнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыгару елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Автотранспорт чарасы MERCEDES-BENZ S 500 4M идентификация номеры (VIN) WDB2201841A469901 җиңел | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2005 | 3,4 квартал |

## 3 Бүлек Хосусыйлаштыруны мәгълүмат белән тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Әлки муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү

барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.